**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2020 Балык Бистәсе штп. №231пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 22 декабрендәге 354пи номерлы карары белән расланган "2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү" Муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 7 мартындагы 510-р номерлы Күрсәтмәсенә таянып КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 22 декабрендәге 354пи номерлы карары белән расланган "2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү" Муниципаль программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның III пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә: "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 7 мартындагы 510-р номерлы Күрсәтмәсе нигезендә 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына спорт мәктәбен җиһазлау өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь алуга 147 600 (йөз кырык җиде мең алты йөз) сум 00 тиен күләмендә башка бюджетара трансфертлар бирелә".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының "Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлеге" МКУ башлыгы И.З. Шакировка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л.Исланов